**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Яңа Аксубай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

№ 4 22 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы ««Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»05.11.2019 ел №111 карары нигезендә түбәндәге сорау буенча 2025 ел 22 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде :

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Яңа Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( шул исәптән Яңа Аксубай торак пункты чикләрендә юл ясау: туфрак күтәрү, вак таш сатып алу, вак таш сибү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү), торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту шул исәптән: урамнарны кардан чистарту ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык - майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу).

**2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- Яңа Аксубай авылында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау ( суүткәргечне ремонтлау, суүткәргеч челтәренең бер өлешен алмаштыру (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

**3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;**

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Яңа Аксубай торак пункты территориясендәге үсентеләрне чаптыру (ягулык-майлау материаллары ,трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу)..

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 198 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 105 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

- «Риза»- 105 катнашучы тавыш бирде;
- «Каршы» -0 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым» 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Яңа Аксубай торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул дип танырга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Яңа Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( шул исәптән Яңа Аксубай торак пункты чикләрендә юл ясау: туфрак күтәрү, вак таш сатып алу, вак таш сибү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү), торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту шул исәптән: урамнарны кардан чистарту ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык - майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу).

**2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- Яңа Аксубай авылында су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау ( суүткәргечне ремонтлау, суүткәргеч челтәренең бер өлешен алмаштыру (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

**3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү,**

**күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;**

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Яңа Аксубай торак пункты территориясендәге үсентеләрне чаптыру (ягулык-майлау материаллары ,трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу)..

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районын рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А.В.Макаров